Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Кутлу-Букашская средняя общеобразовательная школа»
Рыбно-Слободского муниципального района РТ

Принята
на заседании педагогического совета

Протокол от 28.08.2023г. №1

« Утверждаю »
Директор
_________/ Н.Ю.Салахиев/
Приказ №117 о/д от «29» августа 2023г.

**Дополнительная общеобразовательная общеразвивающая программа художественной направленности «Сәхнә теле»**

**Возраст учащихся: 11-12 лет**
**Срок реализации программы: 2 года**

Салахиев Накиф Юнусович
Подписано цифровой подписью: Салахиев Накиф Юнусович
Дата: 2024.03.16 08:20:40 +03'00'

Автор-составитель:
Гайсина Гульфия Габделзуфаровна,
учитель родного языка и литературы

с.Кутлу-Букаш, 2023

## Аңлатма язуы

Программа мәктәпнең үсеш программасы һәм өстәмә белем бирү планы нигезендә төзелә.Түгәрәк эше формасында гамәлгә ашырыла. Эш программасы 5 нче сыйныф укучылары өчен атнага 2 сәгать исәбеннән төзелә. Барлыгы 72 сәгать

Театр – сәнгатьнең бер төре. Ул үз эченә әдәбият, музыка, бию, сынлы сәнгатьне берләштерә. Сәнгатьле сөйләм формалаштырганда балага белем бирү шартлары гына түгел, ә аларны эшкәртергә һәм үзләренең карашын билгеләргә дә мөмкинлек бирә. Моның өчен иң әйбәт чара булып театральлештергән шөгыльләр тора. Театр иң демократик, яшь үзенчәлекләренә туры килерлек сәнгать төре. Ул педагогик һәм психологик актуаль проблемаларны хәл итәргә булыша. Алар әхлак тәрбиясе бирергә, коммуникатив шәхес формалаштырыга, күзаллау, фантазия, инициатива, фикер йөртүгә, туган телне яратырга ярдәм итә. Театр сәнгате аша балалар образлар, тавыш, буяу аркылы әйләнә-тирә белән танышалар, зәвык һәм әхлак тәрбиясе алалар. Тормышның көзгесе булган әлеге сәнгать укучыларны яңа хисләр, белемнәр, күнекмәләр белән баетырга, матур әдәбиятка кызыксыну уятырга, сүз байлыгы, сөйләм телен үстерергә ярдәм итә.

Бүгенге көндә үсеп килүче яшь буынны халкыбызның традицияләре үрнәгендә тәрбияләү- мөһим бурычларның берсе. Балага милли гореф-гадәтләр, милли традицияләр никадәр иртәрәк бирелсә, ул шәхес буларак шулкадәр көчле, телен, илен, милләтен сөя белүче булып үсәчәк.Үз телен, милләтен, мәдәниятен белеп, аңа хөрмәт белән карый белүче генә башка милләт вәкилләрен, аларның гореф-гадәтләрен ихтирам итә белә. Туган телне, милли мәдәниятне өйрәнеп һәм янәшә яшәүче башка халыкларның да теленә, мәдәниятенә, милли традицияләренә тирән ихтирам белән карый белүче балалар безнең мәгариф һәм милли мәдәниятне үстерүнең нигез ташын тәшкил итәргә тиеш.
"Сәхнә теле" түгәрәге укучыларның сәләтләрен ачарга, уй- хыялларын үстерергә мөмкинлек бирә, матурлыкны күрә белергә өйрәтә, иҗади эшчәнлекне баета.

Адәм баласы, укучылар хисләр дәрьясында яши, әйләнә-тирәдә булган вакыйгаларны йөрәге аша үткәрә. Бүгенге укучыларның күңел түрләренә үтеп кереп, аны уйланырга, нәтиҗә чыгарырга, сабак алырга ярдәм итүче иң кулай ысулларның берсе театр сәнгате дип уйлыйм. Җәмгыятьтә үз урыннарын табу, тормышның тайгак юлларында абынмау, үз кыйблаларын саклап калу, иң мөһиме камил шәхес тәрбияләү бурычы өстендә эшләү күз алдында тотыла.

Сайлау курсы дәресләре төрле формада үткәрелә. Күбрәк теоретик һәм практик юнәлештә эш башкарыла. Дәрес-әңгәмә, дәрес-очрашу, дәрес-экскурсияләр үткәрү дә күздә тотыла. Төп игътибар балаларның иҗади сәләтен үстерүгә, аларны милли җанлы, милли рухлы итеп тәрбияләүгә, сәнгатьле һәм образлы сөйләм формалаштыруга, мөстәкыйль шәхес үстерүгә, әзерләүгә юнәлтелә.

Курс 8 сыйныф укучылары өчен төзелә. Актер, журналист һөнәрен үзләштерергә теләүчеләр өчен курсның әһәмияте мөһим.

### Максаты :

1. Укучыларны татар театр сәнгатен аңларга һәм образларны иҗат итәргә өйрәтү.
2. Татар театры тарихы, анын беренче карлыгачлары, беренчел адымнары белән кызыксыну хисләре уяту.
3. Татар театры сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү, әхлак сыйфатлары формалаштыру, киләчәк тормышка әзерләү.
4. Сәнгатьле уку һәм сөйләм күнекмәләрен үстерү.
5. Иҗади сәләтләрен үстерү һәм тирәнәйтү.

### Бурычлары :

1. Театр сәнгатенең мәгънәсен аңлауларына ирешү.
2. Образларны тормышчан иҗат итү серләренә төшендерү.
3. Театрның үткән юлын, аның беренче яралгыларын аңлауларына ирешү.

4. Драма жанрының төрләрен аера алуларын булдыру.
5. Классик әсәрләр сәхнәләштерү.
6. Төрле бәйге-ярышларда, ата-аналар алдында чыгышлар ясау.

**Программасының актуальлеге:**

Кереп баручы стандартларының яңалыгы - белем һәм тәрбия алуда универсаль гамәлләрнең берсе коммуникатив гамәлләрнең камил формалашуы. Ягъни, баланың үз фикерен диалогта һәм монолог рәвешендә башкаларга дәлилле итеп, әңгәмәдәшен кимсетмәслек итеп җиткерә белүгә әзерләү. Бу таләп – түгәрәкнең актуальлеген раслаучы мөһим дәлил дә. Балаларны берләштерүдә, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә, сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үзен-үзе тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур.

1. Балаларның милли культура, театр, артистлар дөньясы турында күп мәгълүмат белүе.
2. Сәхнәләштерү уеннарын үзләштерү ярдәмендә балаларның интонацияләре яхшыру, башка катнашучылар белән аралашу осталыклары арту, килешү, конфликтлы ситуацияләрне чишә белү мөмкинлекләре туу. Балаларның бәйләнешле сөйләм телләре үсү.
3. Сәхнә тормышында үзеңне иркен тоту күнекмәләренә төшенү
4. Үз туган ягыңның сәнгать кешеләре турында мәгълүмат алу.
5. Практика белән теорияне кушып, тулыландыра алу мөмкинлеге булу.
6. Гаилә белән мәктәп арасында җылы мөнәсәббәт тудыру.

**Көтелгән нәтиҗәләр һәм аларны тикшерү төрләре.**

1. Театр сәнгатен башка сәнгать төрләреннән аера.
2. Татар театры тарихы, уткән юлы белән таныш.
3. Сәнгатьле сөйли, образга керә.
4. Актерлык талантына ия.
5. Ижади һәм мөстәкыйль эшли, үз киңәшләрен башкаларга да бирә ала.
6. Драма төрләрен аера, классик әсәрләрне аңлый.
7. Сәхнә тормышы белән таныш, башка милләт театрлары белән дә кызыксына.

**Програма.**

Кереш. (1 сәг.)

Кереш дәрес. Укучыларны туплау, түгәрәкнең эш планы таныштыру. Инструктаж үткәрү. (1 сәг.)

I.**Без – яшь артистлар**. (10 сәг.)

Укучыларның сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. Сәхнә серләренә өйрәнү. Киенү-бизәнү осталыгы турында сөйләшү, видеолардан чыгышлар карау.

II. **Сәхнә уеннары**. (36 сәг.)

Татар халык иҗаты белән танышу. Татар халык иҗатының үзенчәлекләрен билгеләү.
Индивидуаль рәвештә җырлар, биюләр өйрәнү. Киемнәр әзерләү.
Татар халкының сәхнә уеннары, такмак, такмаза, тел шомарткычлар турында мәгълумат бирү.
Сәхнә өчен куелган уеннарны өйрәнү, сәхнәдә кую.
Балаларны парлы, күмәк биюләргә өйрәтү (бию элементларын кабатлау, көйгә басу, киемнәр әзерләү). Бәйрәмнәрдә чыгыш ясау.

III . **Театр-тамаша**. А.Алишның “Үрдәк беренчелекне алган ” әкият-пьесанын өйрәнү, сәхнәгә кую. (23 сәг.)

**Тематик планлаштыру.**

| № | Эш төре | Гомуми сәг. саны | Теоретик сәг. саны | Практик сәг. саны | Дата |
|---|---|---|---|---|---|
| | **Кереш** | | | | |
| | Укучыларны туплау. Түгәрәкнең эш планы белән таныштыру. Инструктаж үткәрү. | **1** | 11 | | |
| **I.** | **Без – яшь аристлар.** | **10** | | | |
| 1 | Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. | | 1 | 1 | |
| 2 | Интонация. Басым. | | 1 | 1 | |
| 3 | Сәхнә серләренә өйрәнү. Видеоязмалар карау. | | 2 | | |
| 4 | Киенү-бизәнү осталыгы. Декорациянең роле. | | 2 | | |
| 5 | Сәхнәдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре. Мимика бирү юллары | | 1 | 1 | |
| **II.** | **Сәхнә уеннары.** | **36** | | | |
| 1 | Мәктәп китапханәсенә экскурсия. Фольклорга караган китаплар белән танышу. | | 2 | | |
| 2 | Татар халык әкиятләре. Әкиятләрнең төрләре. | | 2 | | |
| 3 | Татар халык иҗаты. Җырлар тыңлау. | | | 1 | |
| 4 | Татар халык җырын өйрәнү. | | | 1 | |
| 5 | Татар халык биюе (кызлар өчен). | | | 2 | |
| 6 | Татар халык биюе (малайлар өчен). | | | 2 | |
| 7 | Җырлы-биюле уеннар. | | 1 | 2 | |
| 8 | Такмак такмаза, тел шомарткычлар. | | 1 | 1 | |
| 9 | Тизәйткечләр өйрәнү | | 1 | 1 | |
| 10 | “Табышмак әйтәм - уйлап тап”. Табышмаклар. Аларның төрләре. | | 1 | 1 | |
| 11 | “Капка төбе” җырлы-биюле уены. Сәхнә уенының эчтәлеге белән танышу. | | 1 | 1 | |
| 12 | “Яулык салыш” уенын өйрәнү | | 1 | 1 | |
| 13 | “Йөзек салыш” уенын өйрәнү | | 1 | 1 | |
| 14 | “Кәрия-Зәкәрия” уенын өйрәнү | | 1 | 1 | |
| 15 | Парлы бию “Шома бас” | | | 2 | |
| 16 | Хәрәкәтләрне, бию өлешләрен кабатлау | | | 2 | |
| 17 | Музыкаль бизәлеш. Киемнәр әзерләү. | | | 2 | |
| 18 | Сценарийны кабатлау. Декорация. | | | 2 | |
| 19 | “Капка төбе” җырлы-биюле уены. Әсәрне сәхнәгә кую | | | 1 | |
| **III.** | **Театр-тамаша.** | **25** | | | |
| 1 | “Үрдәк беренчелекне алган ” әкият-пьесаның эчтәлеге белән танышу. Рольләргә бүлеп уку. | | 2 | 2 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2 | Рольләрне кабатлау. Үрдәк роле өстендә эш. | | | 3 | |
| 3 | Сценарийны кабатлау. Әтәч, Тавык, Чеби рольләрен кабатлау. | | | 2 | |
| 4 | Кәҗә, Сыер, Акбай рольләрен кабатлау | | | 2 | |
| 5 | Аю, Төлке, Тиен рольләрен кабатлау. Хәрәкәтләр. | | | 2 | |
| 6 | Сценарийны кабатлау. Музыка. | | | 2 | |
| 7 | Сценарийны кабатлау. Хәрәкәтләр, музыка. | | | 4 | |
| 8 | Киемнәр әзерләү. Сценарийны кабатлау. Декорация. | | | 4 | |
| 9 | Әсәрне сәхнәгә кую. | | | 2 | |
| 10 | Йомгаклау. | | | 1 | |

**Эш формалары**
- әти – әниләр өчен йомгаклау күңел ачу кичәләре;
- әти – әниләрнең фикерләрен өйрәнү;
- кечкенәләр каршында чыгыш ясау;
- татар халык авыз иҗаты, матур әдәбият үрнәкләре белән танышу;
- рольләргә бүлеп уйнау, сәхнәләштерү;
- тел гимнастикасы, артикуляцион күнегүләр ясау;
- экскурсияләр;
- очрашулар;
- әңгәмә, фикер алышулар;
- кул эше, рәсемләү;
- рәсемнәр, иллюстрацияләр, мультфильмнар карау;
- җырлы – биюле, сүзле, өстәл арты уеннары.

5.**Материально-техническое обеспечение образовательного процесса**
- Музыкальный центр;
- музыкальная фонотека;
- СД– диски;
- костюмы, декорации, необходимые для работы над созданием театральных постановок;
- элементы костюмов для создания образов;
- сценический грим;
- видеокамера для съёмок и анализа выступлений.
- Электронные презентации «Правила поведения в театре»
«Виды театрального искусства»
- Сценарии сказок, пьес, детские книги.

**Әдәбият исемлеге**


1) Хәнүз Мәхмутов, Илтани Илялова, Бәян Гыйззәт. Октябрьга кадәрге татар театры. – Казан, 1988.
2) Б.Гыйззәт, Х.Мәхмутов, А.Әхмәдуллин, И.Илялова. Татар совет театры. – Казан, 1975.
3) А.Әхмәдуллин. Сәхнә һәм тормыш. – Казан, 1976.
4) Р.Җиһаншина. Кунелем түреннән.
5) Төрле журналлар, альбомнар, белешмәләр, рәсем-фотолар, артист язмалары.
6) Әдәбият дәреслекләре.
7) Сәхнә әсәрләре
8) Ш.Галиев.Күңелле сәхнә.-Казан, 1971.
9) Ш.Мостафин. Безнең сәхнә. –Казан, 1989.
10) Т.Миңнуллинның “Әлдермештән Әлмәндәр” әсәре